ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
ШӘҺӘР СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

1 июль, 2024 ел № 34/8

Җирле салымнар буенча бурычларны түләттерүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләү турында

Россия Федерациясе Салым кодексының 59 статьясы 3 пункты, «Региональ салымнар суммалары өлешендә бурычны түләттерү ышанычсыз булуны тануга өстәмә нигезләр билгеләү турында» 2024 елның 12 апрелендә кабул ителгән 18-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Шәһәр Уставының 28 статьясы нигезендә
Шәһәр Советы

КАРАР бирде:

1. Җирле салымнар буенча бурычларны түләттерүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләре дип билгеләргә:

1) варислары мирас хокукыннан баш тарткан очракта, варислары булмаган яки мирас ачылган көннән соң бер ел дәвамында мирас алмаган очракта, вафат булган яки вафат булган дип игълан ителгән физик затларның бурычы булу;

2) оешмаларның яки шәхси эшмәкәрләрнең 2024 елның 1 гыйнварына кадәр гамәлдән чыгарылган җирле салымнар буенча бурычлары булу;

3) Россия Федерациясе Салым кодексының 48 статьясында билгеләнгән сроклар тәмамланганнан соң физик затларда 500 сумнан артмаган суммада бурыч булу.

2. Җирле салымнар буенча бурычларны түләттерүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләрен раслаучы документлар исемлеген кушымтага нигезләнеп расларга.

3. Гамәлдән чыккан дип таныргa:

1) «Җирле салымнар буенча түләнмәгән салымнар, пенялар һәм штрафлар буенча бурычларны түләттерүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләү турында» 2020 елның 29 декабрендәге 4/3 номерлы Шәһәр Советы Карарын, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru 2020 елның 30 декабрендә, «Челнинские известия» газетасының 2020 ел, 30 декабрьдәге 97 санында, «Шәһри Чаллы» газетасының 2020 ел, 30 декабрьдәге 97 санында бастырылган;

2) «Шәһәр Советының «Җирле салымнар буенча түләнмәгән салымнар, пенялар

һәм штрафлар буенча бурычларны түләттерүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләү турында» 2020 елның 29 декабрендәге 4/3 номерлы Карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2023 елның 26 гыйнварындагы 20/6 номерлы Шәһәр Советы Карарын Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru 2023 елның 3 февралендә декабрендә, «Челнинские известия» газетасының 2023 ел, 1 февральдәге 7 санында, «Шәһри Чаллы» газетасының 2023 ел, 1 февральдәге 7 санында бастырылган.

**4.** Әлеге Карарның үтәлешен контрольдә тотуны Шәһәр Советының социаль-икътисадый үсеш мәсьәләләре һәм бюджет буенча даими комиссиясенә, Башкарма комитет Җитәкчесе Ф.Ш. Салаховка йөкләргә.

Шәһәр Хакиме Н.Г. Мәһдиев

Шәһәр Советының
34/8 Карарына кушымта
1 июль, 2024 ел

Җирле салымнар буенча бурычларны түләттерүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләрен раслаучы документлар исемлеге

1. Әлеге Карарның 1 пунктындагы 1 пунктчасында күрсәтелгән нигезләр булганда:

а) физик затның теркәлү урыны буенча салым бурычы суммасы күрсәтелгән белешмә;

б) физик затның вафат булуы белән бәйле рәвештә аны салым органнарында исәптән төшерү турында мәгълүмат;

в) мирас хокукы турында таныклык бирү турында мәгълүматлар булмау турында салым органы белешмәсе.

2. Әлеге Карарның 1 пунктындагы 2 пунктчасында күрсәтелгән нигезләр булганда:

а) оешманың, шәхси эшмәкәрнең, шәхси эшмәкәр статусын югалткан физик затның исәпкә алыну урыны буенча салым органының бурыч суммалары турында белешмәсе;

б) салымны гамәлдән чыгару өчен нигез булган норматив хокукый акт турында белешмәләр (исеме, номеры, датасы).

3. Әлеге карарның 1 пунктындагы 3 пунктчасында күрсәтелгән нигез булганда, 500 сумнан артмаган бурыч булуы турында салым органының белешмәсе.